**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ТУЙМЕТКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ТУЙМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

ул.Школьная ,дом 4, с.Туйметкино, 423108
Мәктәп урамы, 4 нче йорт, Туймәт авылы, 423108
тел./факс email: 8-(84396) 3-72-90. Tuy.Cmn.2@tatar.ru

**15 декабрь 2025 ел** **№ 12**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**Туймәт авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 79 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Туймәт авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Туймәт авыл җирлеге Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Туймәт авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 79 номерлы карарына (җирлек Советының 2018 елның 24 августындагы № 87, 2018 елның 15 ноябрендәге № 95, 2020 елның 19

октябрендәге № 6, 2022 елның 16 ноябрендәге № 69, 2023 елның 31 гыйнварындагы № 76, 2024 елның 20 июнендәге № 123, 2024 елның 26 декабрендәге № 140, 2025 елның 16 маендагы № 149 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 өлешнең 3 абзацын бәян итәргә: «Туймәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләме 16928,0 сум тәшкил итә»;

1.2. «Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата түләү күләмнәре» 3 нче кушымтасын яңа редакциядә кушымтада каралганча бәян итәргә.

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Туймәт авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе И.В. Мортазин

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Туймәт авыл җирлеге Советының
2025 елның 15 декабрендәге
№ 12 карарына
кушымта

Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы
авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата түләү күләмнәре

| Вазыйфалар атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Җирлек башлыгы | 23201,0 |